# «Мәңге яши,  яшьни яшь Тукай!»

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан, безнең «Балтач гимназиясе»ндә аның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган төрле чаралар оештырыла. 23нче апрель көнне гимназиянең башлангыч сыйныф укучылары катнашында «Мәңге яши, яшьни яшь Тукай!» - дип исемләнгән әдәби - музыкаль кичә узды. Кичәдә балалар әдипнең шигырьләрен сөйләделәр, әкиятләрен сәхнәләштерделәр, җырлар башкардылар, татар халык уеннарында катнаштылар, Тукай геройлары белән күңел ачтылар. Чара татар халкының гимнына әверелгән Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» җыры белән тәгәлләнде. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның исемен онытмыйча, буыннан буынга җиткерү эшен киләчәктә дә дәвам итәргә язсын.

